

# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№1 Сентябрь 2025 ел*

## Ветеран укытучыларыбыз белән танышуны дәвам итәбез



**Шәрипова Гөлсинә Шәйхетдин кызы.** Жиде яшенә кадәр әти-әниле бәхетле балачагы уза. Әниләре 1939 елда бала тапканда вафат була. Әнисез калган Гөлсинә апа өстенә авырлык өстенә авырлык килеп тора. 1941 елда әтиләренә сугышка китәргә повестка килә. Балалар елый-елый әтиләрен сугышка озаталар. Гөлсинә апаның әтисе ” Борчылмагыз, мин кайтырмын” – диеп балаларын соңгы тапкыр кочаклап, җырлый-җырлый сугышка киткән. Ләкин 1942 елда сугыш кырында бик күп батырлыклар күрсәтеп, үлеп кала.

Гаиләдә 3 ятим бала кала. Гөлсинә апаны һәм балаларны туганнары Апас районы Дәвеш детдомына бирәләр. Детдом балаларын да төрле эшләргә алып баралар, чөнки илдә эшче көчләр җитеп бетми. Басуда коелып калган башакларны җыярга туры килә аларга. Көз көннәрендә Зөя елгасы аша урманга чыбык-чабык җыярга чыкканнар. Детдом Гөлсинә апаны Куйбышев районындагы педучилищега укырга җибәрә. Анда ул 4 ел белем ала.Тәкәнеш районы Түбән Арбаш авылына тәрбияче итеп билгеләнелә. Анда аны балалар *“курчак апа”* дип кенә йөрткәннәр, чөнки ул бик матур, чибәр була. Аннан соң Гөлсинә апаны, үзе дә детдом баласы буларак, Минзәлә детдомына эшкә җибәрәләр. Детдом баласы детдом кагыйдәләрен белә. Анда ул 2 ел эшли. Детдомда эшләгән чорда бик күп куркыныч хәлләргә юлыга. Ул чорда караклар бик күп була. Бервакыт детдомга төнлә белән караклар керә.Тәрбиячеләр көч хәл белән качып калалар. Ләкин Гөлсинә апа зарланмаган.Сугыш афәтеннән ятим калган балаларга әти-әни тәрбиясен дә, назын да биргән. Абыйсы армия сафларыннан хезмәт итеп кайткач, аны үзе яшәгән туган якларына алып китә. Ронога эш сорап баргач, роно мөдире аны Әтнә районы Төрекләр башлангыч мәктәбенә билгели. Мәктәптә 2 ел балаларга белем бирә.Аннан соң Куәм авылына 5-6 сыйныфларга рус теле укытучысы итеп билгелиләр. Берничә ел укыткач, башлангыч сыйныфка күчә.Ә анда башлангыч сыйныф укытучысы булып озак еллар хезмәт итә. 1960 нчы елда Куәмдә укытучы булып эшләгән егеткә кияүгә чыга. Шамил абый белән бергә 44 ел бәхетле гомер кичерәләр, 5 бала тәрбияләп үстерәләр.

**Сөнгатова Гөлнара, тарих укытучысы**

## Җәйге сәяхәт



Бу каникул бигрәк тиз уза да китә икән! Җәйге каникулларның узганын да сизми калдык. Кызыклы сәяхәтләр, күңелле вакыйгалары белән җәй барыбер матур булып хәтердә калды.

Гаиләбез белән без сәяхәт итәргә бик яратабыз. Узган җәйдә Казан, Яр Чаллы шәһәрләренә бардык. Ә иң истә калганы – Йошкар Олага бару булды. Аяз абый җәй башында ук әлеге шәһәргә бару хыялын әйтеп куйган иде. Август аеның матур бер көнендә без юлга кузгалдык. Мари Иленең башкаласы бик якын түгел икән, озак бардык. Юлыбыз калын урманнар аша үтте. Йошкар Ола Казан белән чагыштырганда бик тыныч шәһәр икән, машиналар да, ыгы-зыгы да күп түгел. Без Йошкар Оланың үзәгендәге матур биналарны карап йөрдек, фотога төштек, истәлеккә сувенирлар сатып алдык. Кайтыр юлда нарат җиләге, әтәч гөмбәсе сатып торучы мари кешеләреннән урман күчтәнәчләре дә алдык. Җәйге табигатькә соклана-соклана кайттык, урман буендагы түгәрәк күл буена ял итәргә дә туктадык.

Киләчәктә дә гаилә белән сәяхәт итәргә уйлыйбыз. Туган илебезнең без барып күрергә теләгән шәһәрләре, матур урыннары бик күп әле!

**Айрат Батталов, 2 нче сыйныф укучысы**

## Көз.



Матур, кызу көннәре белән җәйнең үтеп киткәнен сизми дә калдык. Бакчадагы җимешләре, кырдагы игеннәре белән безне сөендереп, җиргә алтын көз килде. Табигать үзенчә матурая. Кызгылт – сары яфраклары белән агачлар сине үз янына тартып тора.

Мин кыр казларының, торналарның тигез итеп тезелеп очканнарын күзәтергә яратам.

Көз житкәч, көннәр кыскара, төннәр озыная башлый. Күп тә үтмәс, агачлардан яфраклар коелып бетәр. Беренче карлар да күренер. Без алтын көзне озатып, салкын, ап-ак кышка керербез.

**Шиһапов Ранель 5 нче сыйныф укучысы**



## Көз - елның матур вакыты

Көз - елның матур вакыты. Көзен яфраклар сары төскә керә, шуңа күрә дә аны алтын көз дип атыйлар. Үләннәр саргаеп кибә. Агач яфраклары җиргә коела. Кояш сирәк күренә. Күк йөзен кара болытлар каплый. Яңгыр пыскып, сибәләп ява. Кискен,усал җилләр исә. Ә шулай да без көзне яратабыз.

Кырларда комбайннар гөрелтесе ишетелә. Кырлар, басулар бушап кала. Комбайнчылар басуларда көннәр буена, ялны белмичә эшлиләр. Бакчаларда да күптәннән инде эшләр башланды, һәммәсе дә, салкын көннәр башланганчы тырышып-тырмашып уңышларын җыялар.

Көз көне без укырга барабыз. Яна белемнәр алабыз. Бу ел фасылын мин шунын өчен бик яратам.

**Закирзянова Дилия 5 нче сыйныф укучысы**

## 1 сентябрь - Белем бәйрәме

Менә тагын җәйләр узды һәм сагынып көтеп алган 1 сентябрь - Белем бәйрәме килеп житте. Бу көнне һәрберебез дулкынланып, шатланып каршы ала: беренче тапкыр мәктәпкә баручы да, өлкән сыйныфларда укучылар да, эти-энилэр дә. Ни дисәң дә, мәктәп еллары - кеше гомеренең иң куанычлы, иң мавыктыргыч чоры.

Чарада районыбыз кунаклары, укытучылар, укучылар, эти-әниләр, ветеран укытучылар һәм башка кунаклар катнашты. Бәйрәмдә мәктәп тормышында актив катнашкан укучылар, укытучылар бүләкләнде, эти-әниләргә рәхмәтләр житкерелде. Уку елының беренче дәресе «Тынычлык дәресе» темасы астында узды. Яна уку елы һәркемгә шатлык-сөенечләр, сәламәтлек, бары тик «4»ле һәм «5»леләр генә алып килсен.

**Брча Айша 8 нче сыйныф укучысы**

## Алда әле зур сынаулар

Барыбыз өчен дә көз яңа уку елы белән ассоциацияләшәдер. Яңа уку елы – яңа тормыш, яңа үзгәрешләр һәм яңа кыенлыклар.

Яңа уку елы – яңа максатлар!Яңа уку елы – яңа мөмкинлекләр! Быел без 9 нчы сыйныфта.Төп бурычлар – яхшы уку, бер-беребезгә ярдәм итү һәм сыйныфта, мәктәптә җылы мөнәсәбәтләр тудыру. Һәр дәрес – белем алу өчен, һәр проект – үзебезне үстерү өчен. Әйдәгез, бергәләп барысына да тырышыйк, өлгерик, имтиханнарны уңышлы бирик!

**Гатауллина Лилия 9 нчы сыйныф укучысы**



## Мизгелләр

Абхазия, Гагра, диңгез,
Кояш балкый нурлары белән.
Мин ял иттем анда,
Онытылмас мизгелләр белән.
Таулар биек, күккә үреләләр.

Матурлыкка карап туймаслык.

Экскурсияләргә йөреп без,
Яңа жирләрне өйрәндек.

**Галявиев Ранил 3 нче сыйныф укучысы**

## «Уф, башланды инде!» димә...

1нче сентябрь көтмәгәндә килә дә житә инде ул, әйеме? Кадерле укучым, җәйге іректе маҗараларга бай тормышны мәктәп, дәресләр, укытучылар, сыйныфташлар һәм таләп-кагыйдәләр алмаштыра. Яңа уку елына ничек жиңелрәк кереп китәргә соң? Берничә киңәш бирим әле.

Йокларга вакытында ят!

Иң мөһим кагыйдә – ул, әлбәттә, көндәлек режимны үзгәртергә әзерләнү. Син әбәт житкәнче йокларга өйрәнгән булсаң, каникулның соңгы көннәрендә үк мәктәп режимына күчә башларга кирәк. Бу кич белән 10нан да калмыйча ятарга һәм 7дән дә калмыйча торырга кирәк, дигән сүз. Югыйсә, укуның беренче атнасында сиңа бик тә, бик тә авыр булачак. Һәм бу рәвешле «җәйдән чыгып житә алмау» укуыңа зыян да салырга мөмкин.

Экран каршыннан кит!

Монысы да бик мөһим киңәш. Сезгә мультфильмнар карау һәм телефонда утыру вакытын яртылаш кыскартырга кирәк. Китапханәнең ишеге кайсы якка ачылганын да искә төшерергә вакыт.

План төзе

Яңа уку елына план төзедеңме соң әле? Каян килеп, диярсең инде син. Ә төзергә кирәк! Тик иң элек узган уку елын искә төшереп алыйк әле. Нинди уңышсызлыклар килеп чыккан иде сезнең? Шулардан чыгып, нинди нәтиҗәләр ясарга була? Уку белән дә бәйле булырга мөмкин алар, дуслар белән мөнәсәбәт, класста абруй-дәрәҗә яулау белән дә.

Яңа уку елында сине бит алда билгеләр генә түгел, кызыклы мәгълүматлар, яңа белемнәр дә көтә әле. Һәм дуслар белән күңелле маҗаралар да. Иң мөһиме – киләсе уку елында мине уңышлар көтә дип уйларга онытма.

Җәйге ялдан соң, мәсьәләләр чишү, дәрес әзерләүләр дә жиңел генә бирелмәс, әлбәттә. Монда да психологлар бик нәтиҗәле эш алымы – «5 минут» теориясен тәкъдим итә. Өстәл артына «Бер 5 кенә минут эшләп алыйм да, аннары 15 минут ял итәрмен», дип килеп утырырга киңәш итә алар. 5 минут эчендә мәсьәлә үзенә җәлеп итәргә дә мөмкин.

Сүз уңаеннан – дәрес әзерләгәндә беренче эш итеп телефоныңны читкәрәк алып куй. Юкса, СМСлар бик нык комачау итәр.

Мәктәп – ул норма!

Әти-әниләрнең эше булган кебек, мәктәп тә синең

өчен нормаль күренеш инде ул. Ә менә каникул – штаттан тыш хәл. Эштә эти-әниләрең хезмәттәшләре белән уртак тел табарга тырышадыр. Син дә мәктәптәге тирәлекне үз коллективың дип кабул итәргә тиеш. Сыйныф житәкчесенең хәлен сорашу, мисал өчен, сиңа аның белән тыгыз элемтәләр урнаштырырга ярдәм итәчәк.

Мөстәкыйль бул!

Укулар башлану синең өчен генә түгел, әниең өчен дә стресс. Әмма син аны стресстан аралый аласың. Моның өчен мөстәкыйльлек кенә кирәк. Мәктәпкә жыену, дәрес әзерләүләр барысы да синең вазыйфалар алар. Әнием булышса, мин әйбәтрәк укыячакмын, дип уйлыйсыңдыр инде. Алай түгел шул. Кешегә салыну – ул синең инде эштән туктавың дигән сүз. Онытма, әниең беркайчан да синең өчен имтиханга керә алмаячак.Минем киңәшләрем сиңа ярдәм итәр дип уйлыйм.

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Садриева А.Г.**



## Көзге уңыш

Мәктәпләрдә укулар башланды. Без 4нче сыйныфта укыйбыз инде.Без сыйныфта дус, тату яшибез.Узган атнада без мәктәбебездә оештырылган “Көзге уңыш” күргәзмәсендә катнаштык.Төрле яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән матур-матур композицияләр ясап килдек . Безгә бу эштә эти-әниләр ярдәм итте. Күргәзмәдә нинди генә эшләнмәләр юк иде!Барлык укучылар да актив катнашты.

**Халитова Иркә, 4 нче сыйныф укучысы**

## Безнең календарь

***06.09. - Китап уку көне***

***15.09. – Жырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Фердинанд Сәлаховка 70 яшь.***

***Драматург Таҗи Гыйззәтнең тууына 130 ел.***

***16.09. -1917 нче елда Сөембикә манарасы очындагы бөркет ярымай белән алыштырылды.***

***Халыкара чисталык көне***

***18.09.-Әдип,Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның тууына 100 ел.***

***20.09. – Мәктәп букчасы көне.***

***21.09. – Халыкара рәхмәтле булу көне.***

***22.09. - Көзге көн белән төн тигезләшкән көн.***

***Язучы, реалистик татар прозасына нигез салучы Заһир Бигиевның тууына 155 ел.***

***Бөтендөнья рәхмәтле булу көне.***

***27.09.-Бөтендөнья туризм көне.***

***30.09.- Халыкара тәрҗемәчеләр көне.***



## Батырлар онытылмас...

23 сентябрь көнне мәктәбебездә бик мөһим чара узды. Якташыбыз, Күәм урта мәктәбендә укыган егетебез, махсус хәрби операциядә батырларча һәлак булган Хәкимжанов Хәлил Хәмбәл улының якты истәлегенә мәктәп музеенда почмак ачылды. Әлеге патриотик чарада Татарстан Республикасының Арча һәм Әтнә районнары хәрби комиссары Вахитов А.Н., Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесе Каюмов А.Ф., Мәгариф бүлеге башлыгы Фатыхов Р.Р., Күәм авыл жирлеге башлыгы Сәмигуллин Л.Ә. һәм, әлбәттә, патриот егетебезнең әнисе Надия апа катнаштылар. Чара барышында якташыбыз турында истәлекләр барланды, хәрби комиссар Надия апага улының "Батырлык өчен" орденын тапшырды һәм Ватанын яратучы батыр ул тәрбияләп үстергәне өчен зур рәхмәт әйтте. Батырларның даны мәңгелек!

**Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Халикова Г.З.**

## 1 октябрь - “Өлкәннәр көне”

Тиздән безнең өчен бик якын булган әби-бабайларыбызның бәйрәмнәре житә.

Әбиләребез безне тәмле ашлары белән сыйлый, безне кочаклап йоклый, бабайлар китап укый, безнең белән уйный. Шуңа күрә без аларны бик яратабыз. “Өлкәннәр көне”нә бүләк итеп үз кулларыбыз белән открытка ясадык, аларны шатландырырга телəдек. Әби-бабайларыбызга нык сәламәтлек, озын гомер телəп калабыз.

**1 нче сыйныф укучылары**





## Чулпан лагеры – дуслык учагы

Әтнә районында урнашкан "Чулпан" лагере – безнең өчен җәйне уткәрергә бик шәп урын булды. Бу лагерьга килү, чыннан да, бер могҗиза кебек тоелды. Лагерьның тирә-ягында биек агачлар, зәңгәр күк йөзе һәм чиста һава безне каршы алды. Бу лагерьда миңа бу елны 2 тапкыр ял иту мөмкинлеге булды. Лагерьның 2 нче сменасында, без класстан 7 укучы бардык, бергә күңелле ял иттек. 4 нче сменада "Апуш" театраль студиясенә йөрүче балалар белән берлектә лагерь оештырылды. "Күзлек" театраль лабораториясе Туфан Миңнуллинның тууына 90 еллыгына багышланды. Без авторның әсәрләренә эскизлар эшләдек, лагерьның йомгаклау чарасы буларак, Камал театрында әлеге эскизларны күрсәттек. Бик күп яңа дуслар таптым.Без төрле уеннарда катнаштык, бу безгә бик күп шатлык китерде.

Лагерьда һәр көн яңадан-яңа кызыклы чаралар үткәрелде. Без иртән зарядка ясап, энергия тупладык, аннан соң төрле ярышларда көч сынаштык. Безнең әйдаманнар бик игътибарлы иде, һәрвакыт безгә ярдәм итәргә әзер тордылар. Алар безне яңа эшләр башкарырга, иҗади булырга өйрәттеләр.Көн саен без 5 тапкыр ашханәдәге тәмле ризык ашадык. Кичләрен без ут янында җыелып, әйдәманарыбыз белән шәм яндырып,көн ничек үтүен сөйләштек,нәтиҗәләр ясап, алдагы көннәргә планнар кордык.

Лагерьда без бик күп яңа әйберләр өйрәндек: бер-беребезне хөрмәт итәргә, бергәләшеп эшләргә, үзара ярдәмләшергә. Дуслык безнең өчен иң кыйммәтле нәрсәгә әйләнде. Чулпан лагере безнең өчен чыннан да 18 көн эчендә икенче йортыбызга әверелде. Күңелле мизгелләр, шатлыклы хәтирәләр безнең белән мәңгегә калачак.Чулпан лагере, без сине сагынабыз, бик яратабыз!

**Галявиева Алия, Күәм урта мәктәбе, 6 нчы сыйныф укучысы**

**Гәҗитне басмага әзерләделәр**
**Баш мөхәррир: Сөнгатова Г.З.**
**8 нче сыйныф укучысы :Шакирова Камилә.**
**6 нчы сыйныф укучысы: Галявиева Алия.**
**10 нчы сыйныф укучысы:Гатауллина Илүзә.**

## Уңай сыйфатлар

Кешегә хас сыйфатлар
Сездә, зыялы затлар!
Һәммәгез тыйнак,матур,
Әхлаклы,гадел, батыр,
Тәрбияле, тәртипле,
Тәуфыйклы,юмарт, ипле,
Акыллы, тырыш, башлы,
Намуслы, кыйгач кашлы,
Тәвәккәл, кыю җанлы,
Бәхетле,шат һәм аңлы;
Ачык, сабыр,гөнаһсыз,
Инсафлы, кара яксыз,
Ихтирамлы,абруйлы,
Ягымлы,чиста уйлы;
Нәзәкәтле, вөҗданлы,
Эшчән, житез һәм данлы,
Олы җанлы, йөрәкле –
Җәмгыяткә кирәкле....
Торам башымны иеп,
Шундый булсаңчы, диеп.

Кадерле укучым! Ленар Шәех атап чыккан һәр уңай сыйфатның сездә дә булуын телим. Тәртипһәм тәуфыйк сезгә гел юлдаш булсын!

## Ребуслар чишәбез

